# УКЫТУНЫ ҖИТЕШТЕРҮЧӘН ХЕЗМӘТ БЕЛӘН БӘЙЛӘҮ ТЕОРИЯСЕНӘ КАРАТА

**М. МӘХМҮТОВ**,
СССР Педагогия фәннәре академиясенең профтехпедагогика фәнни-тикшеренү институты директоры, академик
**В. ИОФФЕ,**
«Педагогика» нәшрияты редакторы

Мәктәп реформасының төп юнәлешләрендә гомуми белем мәктәпләре укучыларын җитештерүчән хезмәткә тарту, һөнәргә өйрәтү, бердәм гомуми белем бирү, укыту процессында актив форма һәм методларны, хисаплау техникасы, компьютерларны киңрәк куллану бурычы куела.

Шулай итеп, безнең алга фән-техника прогрессы шартларында» һәрьяктан кан мил шәхес тәрбияләү белән бергә, укытуны җитештерүчән хезмәт белән бәйләү теориясен үстерү зарурлыгы килеп баса. Әмма шәхес үсешенең, аңарда дөньяга фәнни караш булдыруның нигезен акыл үсешен арттыра һәм тәрбия бирә торган укыту тәшкил итә. Шулай булгач, укыту процессында тулы, бербөтен белем бирү системасы гамәлгә ашырылырга тиеш. Ләкин, укучыларның гомуми белем структурасына анализ нәтиҗәләре күрсәткәнчә, аларның аңында, кагыйдә буларак, бербөтен белем системасы хасил булып бетми.

СССР Педагогия фәннәре академиясенең профтехпедагогика фәнни-тикшеренү институты галимнәре бу өлкәдә тикшеренү эшләре алып бардылар. Тикшеренү нәтиҗәләре профтехучилищеда уку дәверендә кайбер яшьләрдә дөнья га фәнни караш тиешенчә хасил булмавын, алар-да гадәти аң дәрәҗәсе генә (тар карашлылык) тәрбияләнүен, кайберләренең хәтта дөньяга дини караштa торуың да ачыкларга ярдәм итте. Табигать һәм җәмгыять законнары турындагы белемнәрне бәйләнешсез, аерым мораль-этик кагыйдәләрне өстән-өстән генә үзләштерүләре балаларның дөрео юнәлеш алуларына, профессия сайлауларына комачаулый. ,

Безнең институт галимнәре күп кенә укучыларның акыл үсеше белән белем алу омтылышы дәрәҗәсендә зур аерма булуын ачыкладылар. Югарыда күрсәтелгән сфераларның берсендә психологик үсеш тиешенчә булмаса, мондый хәл сагармониялелекжә һәм уку эшенең кирәгеннән артык күбәюенә китерә. Мәсәлән, VII класс укучыларының шактыенда акыл эшчәнлеге һәм хәтерләүнең механик төрләре өстенлек итә, аларда уку эше күнекмәләре җитәрлек түгел. Өлкән класс

укучыларында исә акыл сферасы көчлерәк үсә, ә белем алу ихтыяҗы һәм хисләр дөньясы, шәхес булып үсү процессы акрынрак бара. Бу исә шәхеснең хезмәткә дөрес мөнәсәбәттә булмавыннан килә.

Югарыда күрсәтелгән кимчелекләрнең төп сәбәбе нәрсәдә соң?

Беренче чиратта, фән нигезләрен укытканда бербөтенлекнең булмавын төп сәбәп итеп санарга кирәктер. Бу система күренешләрнең кайбер үзлекләрен (физик, химик һ. б.) генә чагылдыра, ә дөнья, табигать һәм җәмгыять турында тулы белем бирми. Мәсәлән, марксистик философия кешене био-социаль зат дип караса да, мәктәптә бары тик кеше анатомиясе һәм физиологиясе генә өйрәнелә. Күптөрле фән укыту системасының кимчелекләре педагогикага күптән билгеле» Моннан 300 ел элек Я. А. Коменский укучыларда дөньяга караш хасил итүдәге кыенлыкларны әйткән. Предметара бәйләнеш урнаштыру идеясе дә әнә шул вакытта ук күтәрелгән. Педагогика тарихында аның берничә «актив» үсеш чоры булган. . Совет педагоглары соңгы 10 елда бу проблеманы өйрәнүгә бик күл көч куйдылар. 80 нче елларда предметара бәйләнешне укыту программаларына да керттеләр. Ләкин, тәҗрибә күрсәткәнчә» ул укучыларда бербөтен белем системасы хасил итүдә хәлиткеч шарт булып әверелмәде.

Укыту программаларының артык тыгыз, дәреслекләрнең һаман да камилләшеп җитмәве һәм укучыларның күбесендә белем алу теләгенең кискен рәвештә кими баруы — балаларның гомуми белемендә системалылык булмавының икенче сәбәбе.

Кирәгеннән артык эш йөкләү укучыларның сәламәтлегенә зур зыян китерә, аларның буш вакыты бөтенләй калмый. (IX—X класслардагы тырышрак укучыларның атнага 60 сәгать вакыты уку хезмәтенә сарыф ителә.) Укыту программалары артык катлаулы, дәреслекләрнең һәм укыту процессының сыйфаты түбән булуы — моның төп сәбәбе.

Профтехучилище укучыларына аеруча куп эш йөкләнә. Монда һәр дәрестә фән нигезләреннән уртача 3,2 яңа төшенчә бирелә (гомуми белем бирү мәктәбендә һәр дәрестә — уртача 2,8 төшенчә); IX—X класларда— 10 фән, ә ПТУда 20 фән өйрәнелә. Училищеда укучыларның күбесенә мәктәптә сигез ел уку дәверендә төпле белем бирелмәве, аларның танып-белү күнекмәләре дә аз булуы ачыкланды. Мондый укучылар ПТУда IX—X класслар программасын үзләштерә алмыйлар. Шуңа күрә укыту материалын киметергә кирәк. Әмма* физика, математика, химиядән һ. б. фәннәрдән укыту материалларын киметү гомуми урта белем дәрәҗәсен төшерүе ихтимал, бу исә югары белем алуны, укучы шәхесенең

һәрьяклап үсешен тәэмин итмәскә мөмкин. Шулай итеп, дәреслек-ләрдәге һәм программалардагы кайбер темаларны кыскарту кирәклеге белән укы*, туның фәнни-теоретик дәрәҗәсен күтәрү зарурлыгы арасында каршылык барлыкка килә.

Димәк, урта мәктәпләрдә һәм проф-техучилищеларда фән нигезләрен күппред-метлы итеп укытуның традицион системасын үзгәртеп кору турында сүз алып барырга тиешбез. Шәхесне һәм аңарда дөньяга фәнни караш тәрбияләү иң кимендә ике шарт булуын:

а) белем бирү эчтәлеге структурасының «сумматив» (төрле фән белемнәрен арифметик кушу) белемне түгел» ә бәлки бербөтен белем системасын;

б) бербөтен белем системасының укытуны җитештерүчән хезмәт белән бәйләү принцибын истә тотып гамәлгә ашыруны таләп итә.

Хәзерге вакытта мәктәптә укытыла торган гуманитар фәннәр техник һәм технологик белемнәрдән аерып бирелә. Политехник белемнәр минимумы гына бу бушлыкны тутыра алмый.

Укучыларга техник белемнәр профессиональ мәктәптә аерым фәннәрне (гомумтехник фәннәрне — электротехника, материалларның үзенчәлекләрен өйрәнү, машина төзелеше материаллары һәм технологиясе), шулай ук махсус технологияне (токарь, слесарь эшен һ. б. ш.) өйрәнгәндә һәм җитештерүчән хезмәт процессында җиткерелә. Боларның берсе дә гомуми урта белем бирү мәктәбенең укыту планына кертелмәгән. 1958— 1964 елларда урта мәктәпкә җитештерүчән хезмәт кертүне исәпкә алмаганда, укытуны җитештерүчән хезмәт белән бәйләү принцибы ярты гасыр буена гамәлгә ашырылмады.

Табигать турындагы, шулай ук техник һәм гуманитар фәннәрнең үзара тыгыз бәйләнеше җитештерүчән хезмәттә, практикада аеруча ачык чагыла. Хезмәт коллективында исә укшучыларының дөрес аралашу һәм әхлакый, гуманистик, производства мөнәсәбәтләре күнекмәләре, камилләшә, монда' шәхеснең социальләшү процессы тулысынча гамәлгә ашырыла. Шуңа күрә нәкъ менә җитештерүчән хезмәт (анда укыту һәм тәрбия бирү бердәмлеге гамәлгә ашырыла) бербөтен белем системасын барлыкка китерүче фактор булып тора. Индустриаль төрдәге җитештерүчән хезмәттә объектив фикер йөртү нигезендә без өч төрле белемнең (табигать туфындагы белем, техник һәм гуманитар белем), кешенең танып-белү һәм практик күнекмәләрен; иҗтимагый һәм эмоциональ мөнәсәбәтләренең үзара табигый бәйләнешен күрәбез.

Бербөтен белемле шәхес тәрбияләү проблемасы берничә төрле юл белән хәл ителә. Шул арның беренчесе — предметара бәйләнешне тагын да көчәйтү,

икенчесе — хәзерге белем бирү эчтәлеге структурасы нигезендә укытуны җитештерүчән хезмәт белән бәйләү. Өченчесе профессиональ мәктәп бурычларына һәм максатына нигезләнә. Ул, гомуми һәм профессиональ-техник белем бирүнең үзара бәйләнеше нигезендә, яңа фәннәр (предметлар) системасы булдыруны күздә тота. Без моны ике төр мәктәпне якынайтуда да һәм алар-ны киләчәктә берләштерүдә дә иң кулай юл дип саныйбыз.

Ә хәзер укытуны җитештерүчән хезмәт белән бәйләү принцибына кыскача тукта-лып үтик.

Билгеле булганча, укытуны җитештерүчән хезмәт белән бәйләү идеясе капита-лизмның башлангыч чорында ук утопик социализм вәкилләре Томас Мор һәм Том-мазо Кампанелла хезмәтләрендә чагылыш тапкан'. Әлеге идея бөек социалист-уто-пистлар Шарль Фурье һәм Роберт Оуэн хезмәтләрендә тагын да үстерелгән.

К. Маркс һәм Ф. Энгельс укытуны җитештерүчән хезмәт белән бәйләү мәсьәләсенә элегрәк булган фикерләргә тәнкыйть күзлегеннән чыгып якын килгәннәр. Алар акыл хезмәте белән физик хезмәт арасындагы аерманы бетерү, шулай ук тәрбия эшендә теория һәм практиканың бердәмлегенә ирешү, акыл хезмәте белән физик хезмәтне, теоретик һәм практик ганятиеләрне аралаштырып алып бару турындагы фикерләргә югары бәя биргәннәр. Шуның белән бергә, марксизмга нигез салучылар иҗтимагый үсешнең яңа чорына туры килә торган элекке таләпләрне конкретлаштырып, утопик, реаль булмаган арттырып җибәрүләрдән һәм фантастик уйдырмалардан, шулай ук коммунизмны тәфсилләп аңлату кебек башка көрәзәчеләрдән ваз кичү юнәлешендә күп кенә үзгәрешләр һәм өстәмәләр керткәннәр, ягъни социализмны, беренче мәртәбә буларак, утопиядән фән дәрәҗәсенә күтәргәннәр. Бу уңайдан иң әһәмиятлесе шул: К. Маркс һәм Ф.Энгельс пролетар революция җиңүен тулысынча гамәлгә ашыру турында уйлаучы пролетариатның иң мөһим социаль-экономик һәм политик таләбе буларак, укытуны җитештерүчән хезмәт белән бәйләү принцибын алга куйганнар. Капиталистик производствоның машиналы фабрика системасы шартларында К. Маркс һәм Ф. Энгельс балаларны 9 я шьтән хезмәткә тартуны таләп иткәндә, барыннан да бигрәк кул хезмәтен түгел, ә бәлки индустриаль хезмәтне күздә тотканнар. Алар капитализм шартларында ук, берьяклы гына үсешне кисәтү, берничә төрле хезмәтне башкару сәләтенә ия булуга ирешү өчен, барлык кешеләрне дә һәрьяклап үстерергә кирәк диген фикердә торганнар.

К.Маркс һәм Ф. Энгельс укытуны җитештерүчән хезмәт белән бәйләү принцибын җитештерү ысулына, ягъни җитештерү көчләренә һәм җитештерү мөнәсәбәтләренә тамырдан үзгәреш ясарлык чара итеп караганнар. Шулай итеп, белем бирүне хезмәт белән бәйләү эшчене машинага, шулай ук ят иҗтимагый көчләргә һәм шартларга буйсынудан азат итеп, аны шул машиналар, шул көчләр шартлар белән идарә итүчегә әйләндерә. К. Маркс һәм Ф., Энгельс укытуны хезмәт белән бәйләүне социализм өчен көрәш идеясе белән бергә бәйләп караганнар, аннары аны аеруча мөһим гомумпедагогик принцип иткәннәр. Чөнки укытуны җитештерүчән хезмәт белән бәйләгәндә генә, коммунистик җәмгыятьнең һәрьяктан камил кешеләрен әзерләү өчен нигез булдырырга мөмкин.

XVIII гасырда яңа фән — технология барлыкка килә. Ул, куллану әйберләре җитештерү өчен, төрле материалларны эшкәртү һәм кабат эшкәртү ысулыннан файдалануны фәнни нигезли. Маркс әйткәнчә, политехник белем табигать фәннәренә һәм техникага өйрәтүне күздә тотарга тиеш (карагыз: К. Маркс, Ф. Энгельс. Сочинения, 2 нче басма, 23 т., 449 бит). Мондый укыту җитештерү процессларының төп принциплары белән таныштыра һәм бер үк вакытта балага яки яшүсмер-, гә иң гади хезмәт кораллары белән эшләү күнекмәләре бирә.

В. И. Ленин укытуны җитештерүчән Хезмәт белән бәйләү, шулай ук политехник белем бирү турындагы марксистик принципны тагын да үстерә, конкретлаштыра. В. И. Ленин «Народникларның прожектерлык үрнәкләре» дигән мәкаләсендә: «...укытуны яшь буынның җитештерү хезмәте белән кушудан башка, киләчәк җәмгыять идеалын күз алдына китерергә мөмкин түгел: җитештерү хезмәтеннән башка укыту-өйрәтү һәм белем бирү дә, параллель рәвештә укыту-өйрәтүдән һәм белем бирүдән башка җитештерү хезмәте дә техниканың хәзерге дәрәҗәсе һәм фәнни белемнең торышы таләп иткән югарылыкка куела алмас иде»,— дип, укытуны җитештерүчән хезмәт белән кушуның әһәмиятен аңлатты (В. И. Ленин. Әсәрләр, 4 басмадан тәрҗемә, 2 нче том, 463 бит).

К. Маркс, Ф. Энгельс һәм В. И. Ленин политехник белем кешене хезмәт процессын рациональләштерергә сәләтле итүен, аның берьяклы, тар специальләшүдән коткаруын, хезмәт характерын үзгәртүен һәм хезмәтнең тормыш ихтыяҗына әверелүенә булышуын күрсәттеләр.

Хәзер производствоның технологик процесслары җитди үзгәрешләр кичерә — магнит, нур, радиация технологиясе кертелә, технологик процесслар компьютер-лаштырыла. Табигать турындагы фән төшенчәләренә нигезләнеп һәм

күренешләрнең эчке механизмына үтеп кереп, инженерлар һәм галимнәр технологик процессларның яңа параметрларын эзлиләр.

Шуңа күрә, социаль-экономик, социаль-психологик факторларны һәм хезмәтне фәнни оештыру, идарә итү (үзидарә) принципларын, шулай ук социаль экология, эргономика һәм дизайн таләпләрен искә алып, укытуның, җитештерүчән хезмәтнең эчтәлеге, аларның структурасы һәм методикасы җентекләп анализланырга тиеш.

Укучыларга хезмәт тәрбиясе бирүне оештыруда гомуми һәм махсус әзерлекне бер-беренә бәйләү дәрәҗәсе турындагы мәсьәлә дә гаять зур әһәмияткә ия. Монда педагогика фәне өйрәнергә тиешле гомуми, шулай ук вакытлы һәм башка конкрет шартларга бәйле аспектлар да бар. Ләкин хезмәт — тәрбия чарасы буларак, нейтраль процесс. Шуңа күрә җитештерүчән хезмәтне, политехник һәм профессиональ укытуны, әхлак тәрбиясе бирүне үзара бәйләп алып бару мәсьәләсенә тагын да зуррак әһәмият бирергә кирәк. Чөнки хезмәткә бәя бирү өчен, эштә уңышка ирешү мөмкинлеген белү зарури.

Йомгаклап шуны әйтәсе килә: мәктәпнең һәм производствоның тәрбия эшендә уңышка ирешүе өчен, укучыларны тәрбияләүгә, хезмәткә әзерләүгә комплекслы якын килергә кирәк.